ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2019 п.г.т.Алексеевское № 543

**2020 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

В «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2007 елның 12 декабрендәге 482 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслауны кертү турында» 482 номерлы карарына

**карар кылам:**

1. 2020 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар (Кушымта);

2. Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында (Леденцов О.Н.) түбәндәгеләр раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2020 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 02 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет житәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 27 декабрендәге
543 номерлы карарына кушымта

**Алексеевск муниципаль районының**
**гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү**
**интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 90 980 |
| | авыл җирлеге | 92 342 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 137 238 |
| | авыл җирлеге | 141 713 |

**Башкарма комитет**
**эшләре идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**